**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл жирлеге**

---

**КАРАР**
**01.11.2023 ел**

**КАРАР**
**№5**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 21 декабрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 448-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 21 декабрендәге 14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 2 пункты «файдалануга бәйле эшләр башкаруга» сүзләрен «файдалануны гамәлгә ашыруга» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 кушымтаның 2 пунктындагы 22 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Теләсә кайсы типтагы махсус икътисадый зона чикләрендә яисә аңа якын территориядә урнашкан җир кишәрлеге, әлеге махсус икътисадый зонаның инженерлык, транспорт, социаль, инновация һәм башка инфраструктуралары объектларын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башкарма хакимият органы йә Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы, йә идарәче компания белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә вәкаләтләр биргәндә, идарәче компанияне махсус икътисадый зона белән идарә итүгә җәлеп итү турында карар кабул ителгән очракта;»;

2) 1нче кушымтаның 39.10 пунктындагы 7 пунктчасында «белгечлекләр буенча,» сүзләрен «һөнәрләр, белгечлекләр буенча,» сүзләренә, «еллар» сүзен «еллар» сүзләренә алмаштырырга. Россия Федерациясе субъекты Законы белән мондый гражданнар торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торырга яисә әлеге исәпкә кую өчен нигезләр булырга тиеш, шулай ук мондый гражданнарның индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән башка җир кишәрлекләренә милек хокукы булмау турындагы таләпне дә әлеге муниципаль берәмлектә гамәлгә ашырырга тиеш;».

3) 1 нче кушымтаның 39.10 статьясының 2 нче пунктын 2.1 һәм 2.2. түбәндәге эчтәлектәге пунктчалары белән тулыландырырга:

«2.1.) дини оешмаларга, күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә аларга милек хокукындагы биналар, дини яисә хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар урнашса, күрсәтелгән җир кишәрлекләре әйләнештә чикләнгән һәм (яисә) әлеге дини оешмаларга милеккә бирелә алмаса;

2.2.) күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә түләүсез файдалану хокукында үзләренә караган һәм дәүләт яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар урнашкан булса, мондый биналарга, корылмаларга хокуклар туктатылганчы вакытка коммерциягә карамаган оешмаларга;"

4) 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 2 пунктчасында «күчемсез мөлкәтнең әлеге объектлары» сүзләрен «дәүләт яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 1 нче кушымтаның 5 пунктчасында «күрсәтелгән чорда туры китереп» сүзләреннән соң «аның максатчан билгеләнеше һәм» сүзләрен, «муниципаль берәмлек һәм белгечлек буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлек һәм һөнәр, белгечлек буенча» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Имән авыл
җирлеге башкарма комитеты рәисе: Р.Ә.Исламова